РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

---

***Решение*** ***Карар***

**2019 елның 27 нче ноябре Чистай шәһәре №41/1**

2019 елга һәм 2020-2021 еллар план чорына
Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
«Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге
бюджетына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе Карманова Наталья Анфиногентовнаның «2019 елга һәм 2020-2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджетына үзгәрешләр кертү хакында»гы докладын тыңлап фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2019 елга һәм 2020-2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты хакында»гы 2018 елның 25 декабрендәге 30/2 номерлы Чистай шәһәр Советы карарына түбәндәге эчтәлекле пункт өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«2019 елның җәйге чорында халыкның ташламага ия категорияләрен бакчачылык җәмгыятьләренә ташламалы рәвештә йөртүне оештыру турында»гы 2019 елның 30 нчы апрелендәге 34/3 номерлы Чистай шәһәр Советы карары нигезендә һәм 2018 елның 28 нче декабрендәге 33 нче номерлы «Чистай шәһәре халкына маршрут буенча йөрүче пассажир автобуслары белән хезмәт күрсәтү хакындагы килешү»гә таянып, «Экспресс» ҖЧҖгә халыкның ташламалы категориясен бакчачылык җәмгыятьләренә ташыганда, төшеп калган керемнәрне компенсацияләү өчен 500,00 мең сум күләмендә субсидия бүлеп бирергә.».

2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында яисә «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет һәм фаразлау, сәнәгать һәм эшкуарлык буенча даими депутат комиссиясенә Н.В. Миңнегалиевка йөкләргә.

Чистай шәһәре
Чистай муниципаль районы башлыгы Д. А. Иванов